| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.07.2015 Казан ш. № 79

**Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре тарафыннан аларны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында биләгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында**

2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны яки булдыруны, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктының “и” пунктчасы, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы “Коррупциягә каршы көрәш буенча аерым мәсьәләләр турында” 120 номерлы Указының 2 пункты нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 08 июнендәге “Аларны биләгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” ПУ-542 номерлы Указының 2 пунктын үтәү максатында **б о е р ы к б и р ә м:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре тарафыннан аларны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында биләгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки

булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан
Республикасы
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
2015 елның 7
июлендәге 79 номерлы
боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре тарафыннан аларны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында биләгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында, Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 18 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары реестры турында” ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары реестры белән иң югары вазифалар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары:

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары.

---